**МГББУ “ТР Буа муниципаль районы
Боерган урта гомуми белем мәктәбе”**

# “Туган телем – татар теле”

( әдәби- музыкаль кичә)

**Үткәрде:
татар теле һәм әдәбият укытучысы
Әхмәтҗанова Р.Н.**

**2019**

**Максат:**

- туган телгә - ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләү;

- телебезне сакларга һәм якларга кирәклеген төшендерү;

- туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү.

**Җиһазлау:** плакатлар “Без Туган илебезне һәм телебезне яратабыз”, “Туган телне өйрәнү – бөек эш ул”, “Русча белү кирәк, үз телеңне белү тиеш.”; рәсемнәр, Г.Тукай; М.Җәлил портретлары, “Халыкара туган тел көне”нә слайд – шоу.

**А.б.** Без- татарлар, туган телебез татар теле.

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә камилләшкән, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган- сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле! Бүгенге кичәбезне сиңа багышлыйбыз.

**А.б.** Кемнәр генә сиңа сокланмаган һәм мактау җырламаган?! Кемнәр генә синең ярдәмеңдә дөньяны танып белмәгән һәм үзенең уй-хисләрен башкаларга сөйләмәгән?!

И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем.
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.

**А.б.** Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе- анасы өйрәтә, шул телдә аңа бишек

җырларын җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык ана теле дип атый.

**Җыр”Туган тел”**

**А.б..** Әйе, мәшһүр шагыйребез Г.Тукай үзенең туган теленә булган ихтирамын әнә шулай матур итеп әйтеп биргән
Бөек әдип Тукай телне ярата белеп яраткан. Телне ул матур сүзләр җыелмасы итеп кенә карамаган, аны иң элек аралашу, аңлашу, тәрбия коралы итеп тә караган. Шуңа күрә дә телне халыкча итеп, “туган тел”, “матур тел”, “әткәм-әнкәмнең теле” дип атаган.

**Без –татарлар!**(шигырь)

**1 нче укучы.** Без- татарлар!
Татар исемен без
Горур йөртә торган бер халык.
Без- татарлар!
Шулай диеп белә
Безне бөтен дөнья илләре.
Без- татарлар.
Батыр халык дигән
Зур даныбыз әле сүнмәде.
Без- татарлар!
Шушы исем белән
Җирдә яшәү үзе бер бәхет
Без- татарлар!
Яшибез без җирдә
Бар халыклар белән гөрләшеп.

**Җыр”Кояшлы ил”**

**2 нче укучы.** Дөньяда иң-иң матур ил-
Ул минем туган илем.

Дөньяда иң-иң матур тел-
Ул минем туган телем.
“Балам”,- диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
“Әнкәем”,- дип әниемә
Мин туган телдә дәшәм.

**3 нче укучы.** Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

**4 нче укучы.** Мин сөйлим анам телендә
Яшим атам җирендә.
Бу бәхет миңа бирелгән
Туган йорт бишегендә.
Тәүге кабат аяк басып
Сукмактан киттем йөреп.
Әйттем анам теле белән:
-Мин җирдә кеше!- дип

**Җыр “Туган телем”**

**5 нче укучы.** Туган тел- иң татлы тел,
Туган тел- иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма-
Туган телне онытма!
Халкым бер тумыш көндә дә

Тукаен онытмады.

Без-“Туган телд”дән туганнар

Без- Тукай оныклары.

**Җыр”Мин яратам сине, Татарстан!**

**6 нчы укучы.** Татар дигән исемнең тарихы да бик борынгы. Төрле чор галимнәре аны төрлечә аңлатканнар. Кайберәүләр аны “тар-тар” сүзеннән алынган дип уйлыйлар

**7 нче укучы.** Бу фикер безнең халыкка туры килә, чөнки ул сүз бөтен авырлыкны тартыр дигәнне аңлата.

**Татар халык биюе**

**8 нче укучы.** Туган җирем- Идел буе,

Һәр телнең бар туган иле.

Туган җирең кебек назлы,

Җырдай моңлы татар теле.

**А.б.** Бөек кешеләрнең тел турында әйтелгән сүзләр:

“Сүз – бөек нәрсә ул. Бөек, чөнки сүз белән кешеләрне берләштерергә мөмкин, сүз белән дошманлаштырырга мөмкин, сүз белән кешедә нәфрәт уятырга мөмкин”. (Л.Толстой)

“Языку мы учимся и должны учиться непрерывно, до последних дней” (К. Паустовский)

“Халык сөйләмендә тел яшәсә, халык үзе яши, халык сөйләмендә тел үлдеме, тел иясе буларак, халык үзе үлә” (К.Ушинский)

“Туган ил”, “Туган тел” сүзләре һәрвакыт бергә яшиләр, аерылгысыз булып яшиләр” (С.Хәким)

«Билгеле, русча белү бик кирәк, ә үз телеңне белү – тиеш. (Г.Ибраһимов)